## ГАЗЕТА ЧЫГЫШЫННАН СОҢ

*«Дуслык»ның быелгы 11нче санында шәһәребез юллары, тротуарларының кардан начар чистартылуы турында язган идегез инде. Килешегез, язма буенча хәлиткеч чаралар күрелде дип булмый әле. Ни өчен дигәндә, транспорт иң күп йөри торган Совет, Октябрь урамнары тагаракны хәтерләтә бүген. Техника белән йөрү дә, җәяүләп атлау да кыен. Башка урамнарда да юлларның торышы ташка үлчим.*

*Хөрмәтле редакция! Шәһәрдә юлларның торышы өчен махсус җаваплы оешмалар бар бит. Алар үз эшләрен җиренә җиткереп башкарсалар, газета битләрендә күтәрелмичә дә хәл ителә торган проблема бит бу.*

**Х.Вәлиев,**
**шофер.**
**Норлат шәһәре.**

*«Шәһәрдә грипп эпидемиясе көчле булу сәбәпле, бу авырудан иза чигүчеләрнең байтагын, шул исәптән балаларны өйләренә барып карыйбыз. Көн саен берничә дистә адрес буенча өйләрдә булырга туры килә. Әмма юлларның рәтләп чистартылмавы сәбәпле, аларның байтакларына техника белән кереп булмый. Әфган поселогы буйлап билдән кар ерып йөрергә туры килә. Юлларга мондый караш һичкайда юктыр, мөгаен».*

***(Район үзәк шифаханәсе участок табиблары зарыннан).***

# КАР АСТЫНДА... ЮЛЛАР БАР

Чыннан да, юлларыбызның торышы канәгатьләнерлек түгел дисәк, һичкем моны кире какмас, мөгаен. «Дуслык» газетасы да бу турыда язып чыкты. Моңа да карамастан, юлларда җитди үзгәрешләр булмады. Алда китерелгән хат авторлары да билгеліләр моны. Шуңа да без, үз чиратыбызда, юлларның торышы өчен иң зур җаваплы булган НУАД һәм МПП җитәкчеләренә мөрәҗәгать иттек. Түбәндә аларның җавапларын урнаштырабыз.

**Һ.САДЫЙКОВ,**
**НУАД начальнигы:**

Тимер юлның бу ягы, ягъни шәһәрнең төньяк өлешендәге асфальт түшәүле автомобиль юлларының барысы да безнең карамакта. Тротуарлар чистарту исә безнең вазифага керми. Шәһәрне әйләнеп узу юлларының байтак өлешенең торышы өчен дә без җаваплы. Болардан тыш, Норлат - Елховой һәм Яңа Чишмәгә кадәр булган магистраль трасса, Иске Чаллы, Иглай юллары да безнең карамакта. Бу кадәр юлларны тәртиптә тоту өчен махсус техникабыз җитәрлек безнең. Карлар явып, бураннар котырынганда барлык техниканы иртә таңнан ук юлларны чистартуга мобилизациялибез. Аңлашыла ки, иң элек бөтен көчне магистраль юлларга туплыйбыз. Аннан инде, Октябрь , Совет, Карл Маркс урамнары кебек транспорт күп йөри торган урамнарга күчәбез. Газетадагы язмагыз белән килешәм, кайчак читтәге урамнар чистартылмыйча да кала инде. Бу, билгеле, безнең йөзебезне бизәми. Димәк, контрольне көчәйтергә, бу эш өчен җаваплы белгечләр, эшчеләргә җаваплылыкларын арттырырга кирәк.

**Ә.ГАЙНУЛЛИН,**
**ММП начальнигы:**

Шәһәрнең үзәк өлеше, барлык тротуарлар, тимер юлчылар поселогындагы барлык урамнар һәм тротуарлар безнең карамакта. Гомумән, эш фронты зур. Шулай булуга да карамастан, кар - бураннар вакытында барлык кар чистарту җайланмаларыбыз да юлда була. Коллектив тырышмый димәс идем. Тимер юлчылар поселогында тар, вак - вак урамнарның барысын да чистарту максат ителә. Килешәм, ул һәрчак үтәлеп тә бетми инде. Кайчак, ярар , иртәгә дә кар булыр әле, чистартырбыз дип кул селтәвебез сәбәп була моңа. Ә менә тротуарлар мәсьәләсенә килгәндә шуны әйтәсем килә: соңгы вакытта МПП балансында тротуарлар арта, шуңа да юлларның бу четерекле өлешен чистарту өчен махсус техника булмау үзен бик сиздерә. Былтгы карлы - буранлы кыш бу мәсьәләгә җитди якын килү һәм, иң элек, ашыгыч рәвештә махсус техника юнәтү зарурлыгын тагын бер кат раслады.

**РЕДАКЦИЯДӘН: Җаваплар менә шундый. Алардан аңлашылганча, һәр оешма тырыша, һәркайсы тир түгеп эшли. Әмма коры сүзләр белән генә халыкның күзен «буып» булмый шул. Әле менә соңгы көннәрдә яңадан кузгалган кар - бураннар тагын юлларыбызны каплап китте.**

**18 февраль көнне, мәсәлән, МППдан МТЗ - 82 тракторы базасындагы өч бульдозер шәһәрнең үзәк мәйданын кардан арындыру белән мәшгуль иде. Кар төягеч бер агрегат, үзбушаткычлы өч «КамАЗ» автомашинасы ярдәмендә кар шәһәр читенә чыгарылды. РСУдан арендага алынган Т - 150 тракторы исә тимер юлчылар поселогы юлларын чистарту белән мәшгуль иде. Бу кадәр техника белән генә алда телгә алынган күләмдә эш башкару мөмкин булмавы көн кебек ачык, билгеле.**

**НУАД җитәкчелеге дә кар чистарту техникасы көне буе юлларда эшләвен раслады. Әмма моңа карап кына юлларда тулы тәртип урнашмады.**

**Ә инде хатларда телгә алынган хуҗасыз юллы Әфган поселогы юлларына ия табылганлыгын шатланып хәбәр итәбез - Норлат җирле үзидарә Советының соңгы көннәрдә чыгарган карарларының берсе нигезендә әлеге юллар 127 нче ПМК карамагына тапшырылган.**

**Әлегә шундый хәлләр, норлатлылар. Яз сулышын сизәсезме, димәк, карлы - буранлы кыш, шуның белән елның бәлале бу фасылы да тәмамланыр. Үз - үзебезне шулай юатырга гына кала инде.**

**Р.ГИНЯЕВА.**



## ОСТАЗЛАР ЯНӘШӘСЕНДӘ

«Норлат - Октябрь элеваторы» АҖнең смена мастеры Илдар Шәһидуллинның тормышында хәлиткеч чорлар алдадыр әле. Әмма характерындагы биргән сүзендә торучанлык кебек сыйфатына хәзер үк кулланылыш тапты инде ул. Бу коллективка 1992 елда килде Илдар. Башта катнаш азык заводында дозалаучы иде, Бөгелмә индустриаль педагогия техникумын бетергән егетне берничә айдан инде 1 нче производство участогы мастеры итеп күчерделәр.

Мастерның роле нидән гыйбарәт булуы турында коллективта кемнән генә сорама, ул - эштә төп фигура диярләр. Үз коллективын эш белән тәэмин итү турында кайгыртумы, вагоннарны вакытында бушату - төяүне оештырумы, механизмнарның эшен күзәтүме - барысы да мастер җилкәсендә, барысы өчен дә ул җаваплы. Һәм Илдар Шәһидуллин бу вазифаларын җиренә җиткереп башкарырга омтыла, коллективның тырышлыгын да бер максатка туплый. Үзе дә өйрәнә. Район кырларында меңнәрчә игенчеләр тырышлыгы белән үстерелгән ашлык язмышы өчен җаваплылыкны үз өсләренә алган тәҗрибәле остазлар янәшәсендә эшли бит ул.

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

### *Мәдәният*

# АВЫЛ АРТИСТЛАРЫ

Асия репетиция вакытларын бик ярата. Яңа спектакльне алып, артистлар белән киңәшә - киңәшә рольләрне бүлешкәч башлана ул тынгысыз көннәр. Спектакльне өйрәнә башлау - үзе бер тантаналы, изге мизгел. Иң беренче репетициягә һәркем үз күзаллавы, үз иҗади фикерләре белән ашкынып килә. Иң беренчеләрдән булып Васыйл Гафиятуллин килеп керә. Тынгысыз, сәхнәгә чынлап торып гашыйк кеше ул. Шулай булмаса, авыр механизатор хезмәте дә булып та 20 елга якын спектакль уйнап йөрер идеме? Авылдашлары аның «Әниләрем - бәгырьләрем» спектаклендә Җамали, «Сулган чәчәкләр»дә Габдулла, «Татар хатыны ниләр күрми» дә Шаһвәли рольләрен чын күңеле белән бирелеп уйнавын әле дә хәтерлиләр. Ул үзе уйнаячак образны үз күңелендә алдан ук тудырып өлгергән була инде, һәр репетиция саен аңа яңадан - яңа детальләр, хәрәкәтләр, мимикалар өстәп, аны баета, җанландыра бара. Ул яктан Габделхәй Латыйпов фантазиясе - сәләте дә ярлы дип булмый. Берсен берсе кабатламаган «Әскәрали» («Әниләрем - бәгырьләрем»), Габдулла («Сулган чәчәкләр»), Нури («Татар хатыны ниләр күрми») образларын иҗат итте ул. Сәхнәгә чын мәхәббәт нәрсә дә эшләргә сәләтле хис ул: Әнә, Габделхәй хатыны Рәшидәне дә үз араларына тартты. Ул «Татар хатыны ниләр күрми» спектаклендә Фәтхия ролен башкара. Коллективта Рәшит Әһлиуллинның да үз урыны, үз абруе бар. «Шанкар» да Кылычбай, «Кайнаңа»да Аяз рольләрен бик оста башкаруы белән тамашачы күңелендә мәхәббәт яулады ул. Хәзер дә шөгылен ташламый. Гомумән, сәхнә «җене» бер кагылса, кеше аннан тиз генә китә алмый бугай ул. Әнә Исламия Зәйнуллина хәзер Норлатта яши, әмма туган авылы сәхнәсендә әле дә үз кеше ул. Бикүле халык театры шундый талантлар энтузиазмында яши. Ә аның тамыры тагы да еракка - 40 нчы еллар тынгысызларына тоташкан. Ачлы - туклы, хәсрәтле - югалтулы сугыш елларында авылдашларының боек күңелләренә яшәү өмете салган үзешчән артистлар - Газизә апа Кәбирова, Исламия апа Бәхтиярова, Разия апа Әһлетдинова кебек талантлар торган ул чишмә башында. Өлкән бикүлелеләр Исламия апаның моңлы җырлавын, ул иҗат иткән лирик образларны әле дә сагынып искә алалар. Ут кебек җитез, чая Газизә апа тудырган тискәре геройларның да үз яме, үзенә генә хас матурлыгы булган күрәсең, алар телдән - телгә күчеп бүгенге көнгә кадәр елмаеп сөйләнәләр. Өлкәннәрнең аягы җиңел булган - театр бүген дә яши, иҗат итә. Хәзер танылган урта буын артистлар янына талантлы яшьләр - укытучылар Мансур Әһлетдинов, Гүзәлия Хамматова, хуҗалык эшләре мөдире Әнвәр Гыйльфанов, котельня эшчесе Хәлил Шакиров кушылдылар. Аларның һәрберсенең үз йөзе, үз осталыгы, үз иҗади потенциалы бар. Аларда - өр - яңа идеяләр, фантазия ташып тора. Шуңа репетицияләр тулы бер иҗат коллективының эшлекле, бәхәсле, әмма ахыр чиктә уртак фикергә килеп тәмамланган эзләнү мәктәбе рәвешен алалар. Биредә яшьләр тәҗрибә туплый, өлкәннәр яңалык ала. Ә режиссер Асия Ибраһимовага аларның берсенең дә хәтерен калдырмыйча, һәрберсенең файдалы киңәшен кулланып халык театрының үз йөзен саклардай сәнгатьчә отышлы юнәлеш эшлисе генә кала. Театрның исә мәрхүм Гомәр Ибраһимов эшләгән елларда формалашкан йөзе халыкка якын да, кадерле дә. Бүген исә Норлат музыка мәктәбе директоры Т.С.Бәдыйгинның да ярдәме аңа тагы сәнгатьчә югарылыкка ирешергә булыша.

Бикүле авыл халык театры шулай яши, шулай иҗат итә. Хәзер алар Г.Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» әсәре буенча эшләнгән спектакль белән Чистайга, зона смотрына барырга әзерләнәләр. Фидакарь авыл артистларына уңышлар телик.

**С.НУРУЛЛИНА.**

## *Казанга, республика конкурсына!*

Агымдагы айның 25 - 26 нчы числоларында Казанда «Туган ягым - Татарстан» республика конкурсы үтәчәк. Анда безнең районнан балалар музыка мәктәбеннән вокаль ансамбль һәм үзешчән җырчы Нәкыя Мусина катнашачаклар.

